**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 39-9 25 июнь 2021 ел

Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү хакында (2018 елның 30 мартындагы 89-24 номерлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы « Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Указын үтәү йөзеннән,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы
**карар итте:**

1. Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү хакында (2018 елның 30 мартындагы 89-24 номерлы карар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен), санлы финанс активлары, санлы валютаны сатып алу буенча алыш-бирешләр

кылган акчаларны, муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең)соңгы өч елда гомуми керемннән артып киткән очракта, һәм алыш-биреш кылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин